**Республика Татарстан**
**Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2020 № 10

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2007 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлегенең 12 статьясы нигезендә, «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Сарман» газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

«Югары Чыршылы авыл җирлеге»
МБ Советы рәисе И.Н.Камалетдинов